**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 95** **«29» июнь 2018 ел**

**Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә» 2014 елның 12 февралендәге 113 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Карарның гамәлдә булуы имза салынганнан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Т.В. Попова**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл жирлеге Советының 2018 елның 29 июнендәге 95 номерлы карарына кушымта.

**Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибе турында нигезләмә**

1. Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында әлеге нигезләмә Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 31 статьясы, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары, Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә эштән азат ителгән көнгә билгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата түләвенең бишләтелгән күләмендә бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә, муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм аннан соңгы тулы ел эчендә - өстәмә рәвештә муниципаль хезмәткәргә 0,5 акчалата түләү буенча, әмма муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакының ун мәртәбә күләменнән артмаган суммада бер мәртәбә акча түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән киткән көненә билгеләнә.

3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, муниципаль хезмәттән картлык буенча хезмәт пенсиясе алу хокукын бирүче яшькә җиткәч яисә «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләнгәндә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән китүдән тыш, эштән азат ителү аңлашыла.

4. Муниципаль хезмәткәргә җирле үзидарә органын бетергәндә һәм штатны кыскартканда, хезмәткәргә 50 яшь һәм аннан югарырак яшь булганда, 2 пунктта күрсәтелгән муниципаль хезмәт стажы булганда бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына кертелә:

- вазыйфаи оклад;
- класс чины өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- еллык түләүле чираттагы ял алганда бер тапкыр бирелә торган 1/12 күләмендә түләү;
- тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү;

- дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

- муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр кимендә алты ай кала билгеләнгән күләмдә муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

- нормадан тыш шартларда эшләгән өчен компенсация түләүләре;

- вазыйфаи окладка профильле гыйльми дәрәҗә өчен өстәмә.

6. Бер мәртәбә бирелә торган бүләкне түләү турында карар җирле үзидарә органы җитәкчесе - эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан, бер үк вакытта муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында карар кабул итү белән бергә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә кабул ителә.

7. Бер тапкыр бирелә торган бүләк, хезмәт кенәгәсенә тамга куеп, бер мәртәбә түләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгып һәм бер мәртәбә бүләкләү алганнан соң, гражданны муниципаль хезмәткә алганда һәм кабат хезмәт мөнәсәбәтләрен туктатканда бүләк икенче кат түләнми.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле эштән китәргә 30 календарь көн калгач, җирле үзидарә органы (муниципаль орган) бер тапкыр бирелә торган бүләк күләмен билгеләү өчен, Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (алга таба - финанс органы) түбәндәге документларны тапшыра:

8.1. муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата хезмәт хакы турында белешмә, акчалата бүләкләү турында белешмә;

8.2. муниципаль хезмәттә, муниципаль вазыйфада кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган эш стажы турында белешмә;

8.3. кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

8.4. класслы чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керүче вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында норматив актлардан өземтә;

9. Бер тапкыр бирелә торган бүләк, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелми:

9.1. закон нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләк түләнгән очракта, муниципаль вазыйфа биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә.

10. Финанс-бюджет палатасы, җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган документларны карап, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бүләкләү, бер тапкыр акчалата бүләкләү түләү өчен бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамәне, йә җирле үзидарә органына акчалата бүләкләү бирүдән дәлилләнгән баш тартуны җиткерә.

11. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә бер мәртәбә бүләкләүне башкара, бер тапкыр бирелә торган акчаны түли.

12. Бер мәртәбә бүләкләүне бирү әлеге нигезләмә буенча Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге бюджет средстволарыннан гамәлгә ашырыла.